Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлегендә 2023 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**17 октябрь 2022 ел** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге Болгар авылында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының “Болгар шәһәре” муниципаль берәмлеге Болгар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 400,00 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

«Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан православие һәм мөселман зиратлары территориясен төзекләндерү:

- киртә кую (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләрне түләү);
- юллар төзү (смета буенча юллар төзү: вак таш, асфальт сатып алу, нигезне әзерләү, ташу, җәю, эшләрне түләү);
- территорияләрне җыештыру (килешү буенча эшләрне түләү);
- иске кипкән агачларны кисергә (килешү буенча эшләрне түләү).

3. Әлеге карарны «Новая жизнь»- «Яңа Тормыш» район газетасында һәм Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының рәсми сайтында http://spasskiy.tatarstan.ru/, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында: http://pravo.tatarstan.ru/) кабул ителгән көннән алып 10 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Татарстан Республикасы
Спас муниципаль районының
«Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы Ф.В.Мөхәммәтов

СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД БОЛГАР